ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 143-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Д.А. Самаренкин, Л.А. Якунин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 143-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе




Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 24 декабре
№ 489-VII ДС

проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Д.А. Самаренкин, Л.А. Якунин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона һәм Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы оешмалары-резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2006 елның 10 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 2 (I өлеш); 2009, № 1; 2012, № 6 (I өлеш); 2014, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, №17 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәп, үзгәреш кертергә:

«3. Әлеге статьяның 1 өлешендә билгеләнгән салым ставкалары Россия Федерациясе Салым кодексының 284 статьясындагы 8 пункты нигезләмәләрен исәпкә алып кулланыла.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелгән үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2016 елның 13 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2016, № 1 – 2; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш); 2020, № 94 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш), анда «шартларда» сүзеннән соң «, Россия Федерациясе Салым кодексының 284 статьясындагы 8 пункты нигезләмәләрен исәпкә алып» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

«Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2017 елның

2 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 3 өлешенә (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 94 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2024, № 56 (I өлеш); 2025, № 49 (I өлеш), анда «тәртиптә» сүзеннән соң «, Россия Федерациясе Салым кодексының 284 статьясындагы 8 пункты нигезләмәләрен исәпкә алып» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

**4 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә региональ инвестиция проектларын гамәлгә ашырганда салым салуның аерым мәсьәләләрен җайга салу турында» 2022 елның 21 мартындагы 11-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 24 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) беренче абзацта «Региональ инвестиция проектларында катнашучылар» сүзләрен «1. Региональ инвестиция проектларында катнашучылар» сүзләренә алмаштырырга;

2) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

«2. Әлеге статьяның 1 өлешендә билгеләнгән салым ставкасы Россия Федерациясе Салым кодексының 284 статьясындагы 8 пункты нигезләмәләрен исәпкә алып кулланыла.».

**5 статья**

Әлеге Закон 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законы проекты (алга таба – закон проекты) «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе аерым закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчен югалтуын тану хакында» 2025 елның 28 ноябрендәге 425-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 425-ФЗ номерлы Федераль закон) кабул ителүгә бәйле рәвештә эшләнде.

Россия Федерациясе Салым кодексының 284 статьясындагы 1 пунктының дүртенче абзацы (алга таба – Салым кодексы) нигезендә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күчерелергә тиешле оешмалар табышына салымның салым ставкасы Россия Федерациясе субъектлары законнары белән Салым кодексының 25 бүлегендә каралган очракларда аерым категориядәге салым түләүчеләр өчен киметелергә мөмкин.

Хәзерге көндә Татарстан Республикасында оешмалар табышка салым буенча киметелгән салым ставкалары махсус икътисадый зоналары резидентлары булып торучы оешмалар, региональ инвестиция проектларында катнашучы оешмалар, махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар, үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр резидентлары булып торучы оешмалар өчен билгеләнгән.

425-ФЗ номерлы Федераль закон белән Салым кодексының 284 статьясына нигезләмә өстәлә, аның нигезендә 2026 елның 1 гыйнварыннан алып киметелгән салым ставкалары, әгәр оешма тиешле хисап (салым) чорының хисап датасына чит ил агенты статусына ия булган булса яисә аның устав капиталында күрсәтелгән датага чит ил агенты статусына ия булган затлар турыдан-туры һәм (яисә) читләтеп катнашкан булса һәм мондый катнашу өлеше күрсәтелгән датага тулаем алганда кимендә 10 процент тәшкил иткән булса, кулланылмаячак.

Шуңа бәйле рәвештә әлеге закон проекты белән республика законнарын федераль законнарга туры китерү максатларында түбәндәге Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр кертү каралган:

«Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона һәм Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы оешмалары-резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2006 елның 10 февралендәге 5-ТРЗ номерлы;

«Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелгән үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2016 елның 13 февралендәге 5-ТРЗ номерлы;

«Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2017 елның 2 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы;

«Татарстан Республикасы территориясендә региональ инвестиция проектларын гамәлгә ашырганда салым салуның аерым мәсьәләләрен җайга салу турында» 2022 елның 21 мартындагы 11-ТРЗ номерлы.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.